КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 14 февраль г.Казань № 84

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганаклары барлыкка килүне булдырмау һәм аларны бетерү максатларында хайваннарны алуны һәм терлекчелек продуктларын алуны оештыру һәм үткәрү тәртибен, хайваннарны алу һәм терлекчелек продуктларын алу нәтиҗәсендә гражданнарга һәм юридик затларга килгән зыянны каплау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хайваннардан эшләнгән продуктлар һәм чималны эшкәртү һәм саклау предприятиеләрендә дәүләт ветеринария күзәтчелеге турында нигезләмәне һәм хайваннарның аеруча куркыныч авыруларында хайваннарны һәм терлекчелек продукциясен алу тәртибе хакында аңлатманы раслау турында» 2002 ел, 29 гыйнвар, 38 нче карарына үзгәреш кертү хакында

«Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 19 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны алу һәм терлекчелек продуктларын алу турында» 2006 ел, 26 май, 310 нчы карары, «Татарстан Республикасында ветеринария эше хакында» 1993 елның13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары

чыганакларын бетерү, хайваннарның йогышлы авыруларын барлыкка китерүчеләр таралуны булдырмау һәм халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак авырулардан саклау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәге теркәлгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганаклары барлыкка килүне булдырмау һәм аларны бетерү максатларында хайваннарны алуны һәм терлекчелек продуктларын алуны оештыру һәм үткәрү тәртибен;

хайваннарны алу һәм терлекчелек продуктларын алу нәтиҗәсендә гражданнарга һәм юридик затларга килгән зыянны каплау тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хайваннардан эшләнгән продуктлар һәм чималны эшкәртү һәм саклау предприятиеләрендә дәүләт ветеринария күзәтчелеге турында нигезләмәне һәм хайваннарның аеруча куркыныч авыруларында хайваннарны һәм терлекчелек продукциясен алу тәртибе хакында аңлатманы раслау турында» 2002 ел, 29 гыйнвар, 38 нче карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге карар белән расланган хайваннарның аеруча куркыныч авыруларында хайваннарны һәм терлекчелек продукциясен алу тәртибе турында аңлатманы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин